ГЛАВА
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422650, пгт. Рыбная Слобода,
ул. Ленина, дом 48

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

422650, Балык Бистәсе,
Ленин урамы, 48 нче йорт,

Тел.: (84361) 22113, факс: (84361) 23012, e-mail: balyk-bistage@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.01.2020 № 27пг

Балык Бистәсе штп.

**Балык Бистәсе муниципаль районында иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү буенча эшчәнлекне оештыру турында**

Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү мәсьәләләрен хәл итү максатларында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 29 июлендәге “Татарстан Республикасында иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү буенча эшчәнлекне оештыру турында” 631 номерлы карары нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1.Кушымта итеп бирелә торган түбәндәгеләрне расларга:

- иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү мәсьәләләре буенча үзидарәлек ведомствоара комиссия турында Нигезләмәне;
- иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү мәсьәләләре буенча үзидарәлек ведомствоара комиссия составын.

2. Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү мәсьәләләре буенча үзидарәлек ведомствоара комиссиягә иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү буенча чаралар планын эшләргә һәм расларга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты житәкчесе Исланов Р.Л. ка йөкләргә.

Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р. Тажетдинов

Балык Бистәсе муниципаль
район Башлыгының
2020 елның 22 гыйнварындагы
27пг номерлы карары
белән расланды

Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия турында Нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү мәсьәләләре буенча Балык Бистәсе муниципаль районы ведомствоара комиссиясе (алга таба – Ведомствоара комиссия) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгы каршындагы даими эшләүче Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары эшчәнлеген координацияләүне һәм аларның иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, граждан җәмгыяте институтлары, гаммәви мәгълүмат чаралары һәм башка оешмалар белән хезмәттәшлеген оештыруны тәэмин итүче координацияләү (ярашканлыкны тәэмин итү) органы булып тора.

1.2. Ведомствоара комиссия үз эшчәнлегендә федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының үзидарәлек хокукый актлары, шулай ук иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерүгә ярдәм итүне оештыру буенча ведомствоара эшче төркем турындагы Нигезләмәгә таяна.

1.3. Ведомствоара комиссия эшчәнлеге ресоциальләштерүдә ярдәм итү күздә тотыла торган затларның иреклелеге һәм ихтыяр белдерү иреге принципларына нигезләнә.

## II. Ведомствоара комиссиянең төп бурычлары

Ведомствоара комиссиянең төп бурычлары булып тора:

2.1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында иректән мәхрүм итү рәвешендә җинаять җәзасын үтәгән һәм (яки) җинаять-хокукый характердагы башка чараларга дучар ителгән затларга җәмгыятькә җайлашуда социаль-икътисади, педагогик, хокукый характердагы чаралар комплексын тормышка ашыру, шул исәптән:

постпенитенциар озата бару;
һөнәри юнәлеш һәм хезмәттә җайлашу (яраклашу);
торак һәм көнкүрешнең рәтләнүе;
медицина ярдәме күрсәтелү;
психологик ярдәм;
югалган туганлык һәм башка социаль элемтәләрне торгызуда ярдәм итү;

иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерүнең башка рәвешләре.

2.2. Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарының иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, граждан җәмгыяте институтлары, гаммәви мәгълүмат чаралары һәм башка оешмалар белән эшчәнлеген координацияләүне һәм хезмәттәшлеген тәэмин итү.

2.3. Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларның Республика регистрының муниципаль сегментын алып бару.

2.4. Кабат (рецидив) җинаятьчелекне профилактикалау (кисәтү чаралары уздыру).

2.5. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү һәм хезмәт реинтеграциясе буенча алып барыла торган эш турында җәмәгатьчелеккә мәгълүмат җиткерү.

## III. Ведомствоара комиссиянең вәкаләтләре

Ведомствоара комиссия үзенә йөкләнгән бурычларны үтәү максатларында түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

3.1. Индивидуаль тәртиптә ресоциальләштерүдә ярдәм күрсәтүгә ризалык биргән затларның социаль хәлен карый һәм анализлый.

3.2. Законда каралган дәүләт һәм муниципаль ярдәм механизмнарын, башка оешмаларның һәм граждан җәмгыяте институтларының мөмкинлекләрен исәпкә алып, иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затны ресоциальләштерүнең индивидуаль программасын эшли. Тернәкләндерү программасында каралган чараларның һәркайсын гамәлгә ашыру өчен җаваплы затларны, аларны гамәлгә ашыру срокларын билгели.

3.3. Ресоциальләштерү буенча үткәрелгән чараларның нәтиҗәләрен һәм нәтиҗәлелеген анализлый.

3.4. Ресоциальләштерүнең индивидуаль программасын тормышка ашыруны туктату турында түбәндәге очракта карар кабул итә:

тотрыклы уңай нәтиҗәләргә ирешкәндә;

зат Балык Бистәсе муниципаль районыннан читкә даими яшәү урынына күчеп киткәндә (зат Татарстан Республикасы чикләрендә башка муниципаль районга (шәһәр округына) киткән очракта күрсәтелгән факт турында мәгълүмат затка карата булган материаллар белән бергә тиңдәшле муниципаль районның ведомствоара комиссиясенә җибәрелә);

ресоциальләштерүдә ярдәм итүдән баш тартуы турында затның гаризасы кергәндә;

ресоциальләштерүнең индивидуаль программасын алга таба тормышка ашыру мөмкинлеген юкка чыгара торган башка очракларда.

3.5. Балык Бистәсе муниципаль районында кабат (рецидив) җинаятьчелекне профилактикалау мәсьәләләрен хокукый җайга салуны камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерли, аларны вәкаләтле органнарга, вәкаләтле урындагы затларга җибәрә.

3.6. Ведомствоара комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

3.6.1. Үз компетенциясе чикләрендә Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнары, шулай ук дәүләт хакимияте органнары, башка оешмалар һәм граждан җәмгыяте институтлары тарафыннан башкаруга тәкъдим ителгән карарларны кабул итәргә;

3.6.2. Җинаять яки административ җаваплылыкка сәбәп булырдай законнарны бозу билгеләре ачыкланган очракта, гаепле затларны җаваплылыкка тарту мәсьәләсен хәл итү өчен тиешле документларны һәм материалларны хокук саклау органнарына җибәрергә.

3.7. Ведомствоара комиссия үз компетенциясе чикләрендә түбәндәгеләр белән хезмәттәшлек итә (бәйләнешләр булдыра):

3.7.1. Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны исәпкә алу мәсьәләләре буенча Россия Федерациясе җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе;

3.7.2.Түбәндәге мәсьәләләр буенча эчке эшләр органнары белән;

иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны исәпкә алу;

индивидуаль профилактикалау (кисәтү) эшен үткәрү;

хокук белемнәрен пропагандалауда катнашу.

3.7.3. Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы һәм аның карамагындагы учреждениеләр (социаль яклау бүлекләре, халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре, халыкка социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре) белән түбәндәге мәсьәләләр буенча:

1999 елның 17 июлендәге “Дәүләт социаль ярдәме турында” 178-ФЗ номерлы Федераль законны һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 2 сентябрендәге “ Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында, шул исәптән социаль контракт нигезендә” 635 номерлы карарын тормышка ашыру кысаларында иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларга матди ярдәм күрсәтү;

социаль адаптация үзәкләрендә иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затлар арасыннан социаль хезмәтләр алучылары белән билгеле бер яшәү урыны булмаган затлар өчен профилактик эш;

иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче балигъ булмаганнарның, шулай ук ирегеннән мәхрүм итүгә бәйле булмаган җәзаларга хөкем ителгән балигъ булмаган гражданнарның социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрендә социаль җайлашуы (күнегүе);

иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүгә әзерләнүче затларны хезмәт базары, вакансияләр булу-булмау турында мәгълүмат бирү юлы белән ресоциальләштерүгә булышлык күрсәтү;

иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән гражданнарга эшчәнлек (профессия) өлкәсен сайлау, эшкә урнашу, һөнәргә өйрәнү максатларында һөнәри юнәлеш буенча бушлай дәүләт хезмәтләре, билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган күрсәтелгән категория затларга психологик ярдәм буенча, хезмәт базарында эшсез гражданнарга социаль адаптация буенча, һөнәргә өйрәтү һәм өстәмә һөнәри белем бирү буенча түләүсез дәүләт хезмәтләре күрсәтү;

иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән гражданнарга яраклы эш эзләүдә булышлык күрсәтү;

иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны эшкә урнаштырган эш бирүчеләрне стимуллаштыру;

3.7.4. Сәламәтлек саклау территориаль идарәсе, сәламәтлек саклау учреждениеләре тарафыннан беренчел медик-санитария ярдәме, профилактика һәм диспансерлык күзәтүе мәсьәләләре буенча;

3.7.5.Үзләренең компетенцияләре нигезендә башка дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, граждан җәмгыяте институтлары тарафыннан.

## IV.Ведомствоара комиссияне формалаштыру тәртибе

4.1. Ведомствоара комиссия комиссия рәисе, аның урынбасары, сәркатибе һәм комиссия әгъзалары составында төзелә.

Ведомствоара комиссия рәисе:

комиссия эшчәнлеге белән гомуми җитәкчелекне гамәлгә ашыра;

хәлиткеч тавыш хокукына ия буларак комиссия утырышларын алып бара;

ведомствоара комиссиянең чираттагы утырышы көн тәртибен раслый;

үз вәкаләтләре кысаларында комиссия әгъзаларына йөкләмәләр (йомышлар йөкли) бирә;

комиссия кабул иткән документларны имзалый;

ведомствоара комиссиягә йөкләнгән бурычларның үтәлүе өчен персональ җаваплылык тота.

Ведомствоара комиссия сәркатибе:

комиссия рәисе йөкләмәләрен (йомышларын) үти;

комиссия утырышының көн тәртибен формалаштыра, утырышка кирәкле материалларны, тиңдәшле карарлар проектларын әзерләү буенча эшне координацияли (яраштыра), комиссия утырышы беркетмәсен алып бара;

Ведомствоара комиссия әгъзаларына, утырышка чакырылган затларга утырышны уздыру урыны, вакыты, көн тәртибе турында хәбәр бирә, аларны кирәкле материаллар белән тәэмин итә;

җәза үтәтү системасы учреждениеләреннән затның алда торган азат ителүе, аның торагының булу-булмавы, хезмәткә яраклылыгы һәм белгечлекләре турында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарына килеп ирешүче мәгълүматны җыюны һәм гомумиләштерүне гамәлгә ашыра;

иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затлардан ресоциальләштерүгә булышлык күрсәтү турында гаризалар кабул итүне гамәлгә ашыра;

ресоциальләштерү программасында катнашучы һәркемгә озату картасы ( карта сопровождения) һәм шәхси эш рәсмиләштерә, аңа ресоциальләштерү индивидуаль программасы чараларын үтәү буенча документлар һәм мәгълүматлар кертелә;

иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затлар Республика регистрының үзидарәлек сегментын алып бара;

җирле үзидарә органнарыннан, дәүләт хакимияте органнарыннан, җәмәгать һәм башка оешмалардан һәм урындагы затлардан Ведомствоара комиссия эшчәнлеге өчен кирәкле документларны, материаллар һәм мәгълүматны соратып алдыра;

Ведомствоара комиссиянең утырыш беркетмәләрен рәсмиләштерә;

комиссия рәисенең утырыш нәтиҗәләре буенча биргән йөкләмәләрен үтәүне оештыра;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы халкына Ведомствоара комиссиянең функцияләре, аның эшчәнлеге нәтиҗәләре турында мәгълүмат бирүне оештыра.

4.2. Ведомствоара комиссия составы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгы боерыгы (күрсәтмәсе) белән раслана.

4.3. Ведомствоара комиссия составына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт хапкимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, социаль яклау органнары, сәламәтлек саклау, мәгариф органнары (килешү буенча) вәкилләре керергә мөмкин.

4.4. Ведомствоара комиссия составына ресоциальләштерүдә уңай тәҗрибәгә ия булган иректән мәхрүм итү урыннарыннан элек азат ителгән затлар кертелергә мөмкин.

4.5. Ведомствоара комиссия утырышларында Балык Бистәсе районы прокуратурасы вәкиле (килешү буенча) катнашырга хокуклы.

4.6. Ведомствоара комиссия утырышларына дәүләт хакимияте органнарының, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарының комиссия составына кермәгән вәкилләре, шулай ук бүтән оешмаларның, граждан җәмгыяте институтлары һәм гаммәви мәгълүмат чаралары вәкилләре чакырылырга мөмкин.

4.7. Ведомствоара комиссия эшендә катнашу җәмәгатьчелек башлангычында гамәлгә ашырыла.

## V. Ведомствоара комиссия эшчәнлеген оештыру һәм аның эш тәртибе

5.1. Ведомствоара комиссия эше даими нигездә гамәлгә ашырыла.

5.2. Ведомствоара комиссия утырышлары иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затлардан ресоциальләштерүгә булышлык күрсәтү турында гаризалар керүгә карап уздырыла, ләкин айга бер мәртәбәдән дә ким түгел. Зарурлык булганда, Ведомствоара комиссия рәисе, аның урынбасары, шулай ук комиссия әгъзасы (рәис белән килешү буенча һәм комиссия сәркатибе тәкъдиме буенча) инициативасы белән Ведомствоара комиссиянең чираттан тыш утырышлары уздырылырга мөмкин.

5.3. Ведомствоара комиссия утырышларын аның рәисе алып бара, ә ул булмаганда яисә аның йөкләмәсе буенча – комиссия рәисе урынбасары.

5.4. Ведомствоара комиссия утырышының вакыты һәм урыны турында ресоциальләштерүгә булышлык күрсәтү турында гариза кергән затларга, аларның туганнарына, утырышта катнашулары максатка ярашлы дип таныла торган бүтән затларга утырыш көненнән алдан бер тәүлектән дә соңга калмыйча хәбәр ителә.

5.5. Ведомствоара комиссия утырышының вакыты һәм урыны турында Балык Бистәсе прокурорына хәбәр ирештерелә.

5.6. Ведомствоара комиссия утырышы комиссия составының яртысыннан артыгы катнашканда вәкаләтле санала.

5.7. Ведомствоара комиссия карарлары тәкъдим, киңәш сыйфатына ия һәм алар утырышта катнашучыларның ачык тавыш бирүендә гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар саны тигез булганда рәислек итүче тавышы хәлиткеч көчкә ия.

5.8. Ведомствоара комиссия әгъзалары утырышта карала торган мәсьәләләр буенча фикер алышканда бертигез хокукка ия.

5.9. Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән зат теләге буенча утырыш әлеге Нигезләмәнең 4.6 пунктында күрсәтелгән затларны чакырмыйча уздырыла.

5.10. Ведомствоара комиссия әгъзалары комиссия утырышында тикшерелә торган сораулар турындагы мәгълүматларны әлеге сораулар кагылган затларның ризалыгыннан башка сөйләп йөрергә (фаш итәргә) хаклы түгел.

Гражданнарның шәхси тормышы турындагы мәгълүматларны тараткан өчен Ведомствоара комиссия әгъзалары закон нигезендә җаваплы була.

5.11. Ведомствоара комиссия эшен гаммәви мәгълүмат чараларында яктырту максатларында Ведомствоара комиссия рәисе рөхсәте белән гаммәви мәгълүмат чараларына персональ мәгълүматларны күрсәтмичә генә тиешле мәгълүматны бирү рөхсәт ителә.

Балык Бистәсе муниципаль
район Башлыгының
2020 елның 22 гыйнварындагы
27пг номерлы карары
белән расланды

# Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия составы

| | |
|---|---|
| Әхмәтжанова Фирдания Гомәр кызы | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгы урынбасары, комиссия рәисе |
| Вафина Айгөл Камил кызы | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары, комиссия рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Ризаева Алсу Нәҗип кызы | “ТР ХМ һәм СЯМ ның Балык Бистәсе районындагы “Доверие – Ышаныч” ХСХККҮ” ДАСХКУ директоры (килешү буенча), комиссия сәркатибе |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Фатыйхов Марсель Рамил улы | Россия ЭЭМ ның Балык Бистәсе районы буенча бүлегенең җәмәгать тәртибен саклау буенча полиция башлыгы урынбасары, полиция подполковнигы (килешү буенча) |
| Исмәгыйлев Рафаэль Дәүләтьяр улы | ТР ХМ һәм СЯМ ның Балык Бистәсе муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Хәбибуллин Ленар Рафаэль улы | Россия ЭЭМ ның Балык Бистәсе районы буенча бүлегенең полиция участок уполномоченныйлары хезмәте башлыгы, полиция капитаны (килешү буенча) |
| Крайнов Александр Владимирович | ТР буенча Россия “ҖҮИ” ФКУ нең Балык Бистәсе районы буенча филиалы башлыгы, эчке хезмәт майоры (килешү буенча) |
| Әлмөхәммәтова Әлфия Мөхәммәтҗан кызы | Россия ЭЭМ ның Балык Бистәсе районы буенча бүлегенең миграция мәсьәләләре буенча бүлекчәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Гаязова Энҗе Шамил кызы | “Балык Бистәсе РҮХ” ДАССУ баш табибы урынбасары (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Зарипова Миләүшә Фатыйх кызы | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының ГХАТ бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Садиков Илсур Мансур улы | “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф бүлеге”МКУ башлыгы (килешү буенча) |
| Гыйзетдинов Фәрит Габделхәй улы | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгының иминлек буенча киңәшчесе |
| Керженцева Гүзәлия Фәйзерахман кызы | “Халыкның мәшгульлек үзәге”ДКУ башлыгы (килешү буенча) |
| Иминева Рәйханә Габделбәр кызы | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, “Балалар иҗат үзәге” ӨББ УБУ директоры (килешү буенча) |
| Габдрахманова Гөлчирә Гаязетдин кызы | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының ББЭ һәм АХЯК нең җаваплы сәркатибе (килешү буенча) |
| Хәкимуллин Айрат Альберт улы | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге башлыгы (килешү буенча) |